ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

| ***Постановление*** | | ***Карар*** |
|---|---|---|
| **18.03.2024** | **Чистай шәһәре** | **№ 95** |

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 июнендәге 367 номерлы карары белән расланган спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Прокурорның өлкән ярдәмчесе Салихов Р.Р. катнашында Чистай шәһәр прокуратурасының 2024 елның 6 мартындагы 02-08-02-2024 протестын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, Россия Федерациясе Спорт Министрлыгының «Бердәм Бөтенроссия спорт классификациясе турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 19 декабрендәге 1255 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 июнендәге 367 номерлы карары белән расланган спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1.2. Хезмәт күрсәтүне алучылар: «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Спорт министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлеккә кертелгән региональ спорт федерацияләре, территориаль эшчәнлек өлкәсе урыны буенча җирле спорт федерацияләре, физкультура-спорт оешмалары».;

1.2. 2.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Спорт разряды бирү өчен документларны карау срогы аларны теркәгән көннән алып 16 эш көне тәшкил итә.

Спорт разряды бирү турында яисә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итү спорт разряды бирү өчен документлар каралып беткән көннән алып 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Спорт разряды бирү турындагы карар оешма җитәкчесе имзалаган боерык белән рәсмиләштерелә.»;

1.3. 2.5.1 пунктының 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) судьялар коллегиясе рәисе (баш судья) имзалаган судьялар коллегиясе составы һәм квалификациясе турындагы белешмә күчермәсе (халыкара ярышлардан тыш);»;

1.4. 2.5.1 пунктының 10 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.5. 2.5.1 пунктының 15 абзацында «туу турында таныклык.» сүзләреннән соң «документларны электрон рәвештә тапшырганда туу турында таныклыктан белешмәләр тиешле кырларга интерактив портал формада кертелә һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, запрос җибәрү юлы белән тикшереләчәк. Туу турында таныклык чит телдә бирелгән булган очракта, төп нөсхәсен һәм аның нотариаль расланган тәрҗемәсен күрсәтергә кирәк. Документларны электрон формада тапшырганда, нотариусның ЭЦП имзалаган нотариаль таныкланган тәрҗемә бирелә.»;

1.6. 2.10 пунктның 2 абзацында «кирәкми» сүзләреннән соң түбәндәге сүзләрне өстәргә: «Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2011 елның 21 июлендәге 10/3 номерлы Чистай муниципаль районы Советы карары нигезендә»;

1.7. 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.7 пункт өстәргә:

**«3.7. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең күрсәтелгән хезмәтләрне мөрәҗәгать итүчеләрнең гомуми билгеләргә берләштерелгән аерым категорияләренә күрсәтү тәртибен үз эченә алган вариантлары.**

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе әлеге Административ регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең гомуми билгеләре белән берләштерелгән категорияләргә бәйле түгел. Шуңа бәйле рәвештә, гомуми билгеләр белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен, шул исәптән алар сорап мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, үз эченә алган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары билгеләнми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат

порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов